Республика Татарстан
Менделеевский муниципальный район
Глава Брюшлинского сельского
поселения

Татарстан Республикасы
Менделевск муниципаль районы
Бөрешле авыл җирлеге башлыгы

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                                  КАРАР
26 март 2024 ел                                                  №1

2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы
«Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге составына керүче
Бөрешле авылында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында", 2023 елның
30 ноябрендәге 2 номерлы " 2024 елда
Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең
Бөрешле авылында гражданнарның
үзара салымнарын кертү турында"
гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр
кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елның 6 апрелендә 17.00 сәг. 2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Бөрешле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 30 ноябрендәге 2 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы, Бөрешле авылы, Заречная ур. 14 й. адресы буенча урнашкан Бөрешле авыл мәдәният йортында гражданнар җыенын уздырырга.

2. 2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге

составына керүче Бөрешле  авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында",  2023 елның 30 ноябрендәге  2 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы  Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында   гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсенә сез ризамы” дигән  сорауны гражданнар җыенында расларга һәм түбәндәгечә бәян итәргә:

«1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Бөрешле авылында вак таш җәелгән юлларда  чокырлы ремонтлау; Бөрешле авылында юлларны кардан чистарту);

2) су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су өчен электр насослы   скважина агрегаты сатып алу);

3) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасына янгын сүндерү җиңен алу);

4) торак пункт территориясен төзекләндерү (Бөрешле авылындагы территорияне чабу)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштырып игълан итәргә, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru « Бөрешле авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru    урнаштырырга.

4. Әлеге карар  игълан ителү көненнән үз көченә керә.

Бөрешле авыл җирлеге башлыгы Л.А.Смирнова